ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.06.2015 № 160

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр (метрополитенны кертеп), шәһәр яны һәм шәһәрара элемтәсендә җәмәгать транспортының барлык төрләрендә (тимер юл транспортыннан тыш) пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифлар билгеләү турындагы эшләрне карап тикшерү Тәртибен раслау хакында» 2013 елның 11 июнендәге 159 санлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым законнарына хуҗалык җәмгыятьләренең мөһергә ия булу мәҗбурилеген юкка чыгару өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 82-ФЗ санлы Федераль закон таләпләренә туры китерү максатыннан,

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр (метрополитенны кертеп), шәһәр яны һәм шәһәрара элемтәсендә җәмәгать транспортының барлык төрләрендә (тимер юл транспортыннан тыш) пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифлар билгеләү турындагы эшләрне карап тикшерү Тәртибен раслау хакында» 2013 елның 11 июнендәге 159 санлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүче Дәүләт комитетына үз җитәкчесенең имзасы куелган һәм гариза бирүченең мөһере белән расланган (мөһергә ия булганда) гариза һәм материаллар тапшыра.»;

7 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документларның күчермәләре гариза бирүченең җаваплы затлары тарафыннан һәм гариза бирүченең мөһере белән (мөһергә ия булганда) расланырга тиеш.».

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисе урынбасары Д.А.Симкачевка йөкләргә.

Рәис М.Р.Зарипов